Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел №96

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 90 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Ямаш авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 90 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 130 номерлы, 2015 елның 05 маендагы 146 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 104 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы, 2021 елның 02 августындагы 23 номерлы ,2023 елның 14 декабрендәге 86 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорты, Зәй-Чишмә авылы, Верхняя урамы, 186 йорт, Березовка авылы, Горная урамы, 46 йорт, Нолинка авылы, Лесная урамы, 3 йорт, Петровка пос., Үзәк урам, 10 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ямаш авыл
җирлеге башлыгы Е.С.Ларин